КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 ел, 1 июль

г.Казань

№ 617

Шәһәр яны элемтәсенең җайга салына торган тарифлар буенча Татарстан Республикасы территориясеннән уза торган даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын оештыру чаралары планын («юл картасын») раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Шәһәр яны элемтәсенең җайга салына торган тарифлар буенча Татарстан Республикасы территориясеннән уза торган даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын оештыру чаралары планын («юл картасын») расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясе буенча узучы шәһәр яны маршрутларында җайга салына торган тарифлар буенча 2018 – 2020 елларда даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2018 ел, 19 апрель, 261 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 июль, 617 нче
карары белән расланды

Шәһәр яны элемтәсенең җайга салына торган тарифлар буенча
Татарстан Республикасы территориясеннән уза торган даими пассажирлар йөртү һәм
багаж ташу маршрутларын оештыру чаралары планы («юл картасы»)

| Т/с | Җайга салына торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өчен кирәкле чаралар | Документ төре | Башкаручы | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Транспорт чарасының классына бәйле рәвештә, даими пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның 1 километр юлы өчен чыгымнар нормативларын раслау | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | ел саен, 1 гыйнварга кадәр, узган ел дефлятор индексын кулланып |
| 2. | Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль районнары өчен җайга салына торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга иң чик максималь тариф билгеләү:<br>Әгерҗе муниципаль районы,<br>Азнакай муниципаль районы,<br>Аксубай муниципаль районы,<br>Актаныш муниципаль районы,<br>Алексеевск муниципаль районы, | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Әлмәт муниципаль районы,<br>Апас муниципаль районы,<br>Арча муниципаль районы,<br>Баулы муниципаль районы,<br>Балтач муниципаль районы,<br>Бөгелмә муниципаль районы,<br>Буа муниципаль районы,<br>Югары Ослан муниципаль районы,<br>Биектау муниципаль районы,<br>Чүпрәле муниципаль районы,<br>Алабуга муниципаль районы,<br>Зәй муниципаль районы,<br>Зеленодольск муниципаль районы,<br>Кайбыч муниципаль районы,<br>Кама Тамагы муниципаль районы,<br>Кукмара муниципаль районы,<br>Лаеш муниципаль районы,<br>Лениногорск муниципаль районы,<br>Мамадыш муниципаль районы,<br>Минзәлә муниципаль районы,<br>Түбән Кама муниципаль районы,<br>Яңа Чишмә муниципаль районы,<br>Нурлат муниципаль районы,<br>Питрәч муниципаль районы,<br>Балык Бистәсе муниципаль районы,<br>Саба муниципаль районы,<br>Сарман муниципаль районы,<br>Спас муниципаль районы,<br>Тәтеш муниципаль районы,<br>Тукай муниципаль районы, | | | пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен җайга салына торган тарифларны билгеләү тәртибе нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Теләче муниципаль районы,<br>Чирмешән муниципаль районы,<br>Чистай муниципаль районы,<br>Ютазы муниципаль районы | | | |
| 3. | Бу Шәһәр яны элемтәсенең җайга салына торган тарифлар буенча Татарстан Республикасы территориясеннән уза торган даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын оештыру чаралары планының («юл картасының») (алга таба – «юл картасы») 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнар нормативын һәм Татарстан Республикасында шәһәр яны элемтәсендә автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен законнар нигезендә билгеләнгән иң чик максималь тарифларны күздә тотып, 0,5кә тигез булган автобус тулу коэффициентын куллануны һәм көненә кимендә ике круг рейс ясауны исәпкә алып, даими пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның һәр маршруты буенча финанслауга ихтыяҗ суммасының исәп-хисаплары | | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | ел саен, 1 сентябрьгә кадәр |
| 4. | «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга һәм даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары карталарын алу | | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) | «юл картасы»ның 3 пунктын үтәгәннән соң, 30 календарь көн үткәч (алга таба – ел саен, 1 декабрьгә кадәр) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | хокукына бәйле хезмәтләр күрсәтүгә сатып алуларны оештыру һәм гамәлгә ашыру | | | |
| 5. | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында җайга салына торган тарифлар буенча беренче һәм соңгы тукталыш пункты булып Яр Чаллы шәһәре торган даими пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның шәһәр яны муниципальара маршрутларында җайга салына торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга һәм даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары карталарын алу хокукына бәйле хезмәтләр күрсәтүгә сатып алуларны оештыру һәм гамәлгә ашыру | муниципаль контракт | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) | «юл картасы»ның 3 пунктын үтәгәннән соң, 30 календарь көн үткәч (алга таба – ел саен, 1 декабрьгә кадәр) |
| 6. | Муниципаль контракт төзү | муниципаль контракт | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) | «юл картасының» 5 пунктын үтәгәннән соң, законнарда билгеләнгән срокларда (алга таба – ел саен, 1 декабрьгә кадәр) |
| 7. | Җайга салына торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны башкаруны мониторинглау | | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) | квартал саен |

_______________